ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2020 Олы Кайбыч авылы № 276

«Опека һәм попечительлек өлкәсендә күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2009 елның 8 августындагы 361 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешенең 16 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында» 2019 елның 18 июлендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законга, «Ана (гаилә) капиталы чаралары белән эш итүгә бәйле мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына инвалидлык турында белешмәләр бирү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 10 февралендәге 114 номерлы карарына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Опека һәм попечительлек өлкәсендә күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 8 августындагы 361 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«инвалидлык турында инвалидларның Федераль реестрындагы белешмәләр. Федераль инвалидлар реестрында тиешле мәгълүматлар булмаган очракта, хезмәт күрсәтү турында карар мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлар нигезендә кабул ителә.»;

2 нче кушымтаның 3.3.3 пунктның «к» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«к) балигъ булмаган балага инвалидлык турында белешмә (билгеләнгән үрнәктәге), аның индивидуаль реабилитация яки абилитация программасы яки балигъ булмаган балага инвалидлык билгеләү фактын раслаучы белешмәләр,

шулай ук аны реабилитацияләү яки абилитацияләү буенча рекомендацияләр булган белешмәләр;»;

20 нче кушымтаның 2.5 пунктының 5 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Биккуловага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров